| ГЛАВА<br>Крындинского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Кырынды авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.11.2025 Кырынды авылы № 2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тукай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Татарстан Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тукай торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 25 ноябренә 09 сәг. 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

2.1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының» Кырынды авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең Тукай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган затларны, ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затларны, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгәннәрне, ирекләләрне һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, ир белән хатыны, балигъ булган балалары)) тыш, 2026 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертүгә һәм түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә, файдалануга ризамы?:

1. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (чишмәне ремонтлау өчен материаллар сатып алу һәм территорияне чистарту, су белән тәэмин итүне карап тотуның башка чыгымнары)

«РИЗА» «КАРШЫ»

2.2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының» Кырынды авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең Тукай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә 2026 елга гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 31.10.2025 №1 карарны гамәлдән чыгарырга ризамы? «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары үз көчләрен югалткан дип танылды

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Тукай авылы, Тукай ур., 17нче йорт, фельдшер-акушерлык пункты территориясендә.

4. Җыенны оештыруны һәм үткәрүне Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга(http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы : Р. Р. Мәүликәев

